**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_14.08.2021_ ___876-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2020 елның 13 апрелендәге 481-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә һәм Татарстан Республи-касында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файда-лану хокукына аукцион уздыруның үрнәк тәртибе һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министр-лыгының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2020 елның 13 апрелендәге 481-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә, Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.8 пунктта «www.eco.tatarstan.ru» сүзләрен «https://eco.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга;

7.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6. Әгәр Аукцион әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктындагы «а»-«г», «е» һәм «ж» пунктчаларында каралган нигезләр буенча узмаган дип танылса, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Респуб-

ликасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү әлеге Нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына Аукцион әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктындагы «д» һәм «з» пунктчаларында каралган нигез буенча узмаган дип танылса, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы Аукционда бердәнбер катнашучыга яисә Аукционда катнашып, бер тапкыр түләүнең башлангыч күләмен раслаган затка Аукцион шартларында, җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә, ул бер тапкыр түләнә торган түләүнең Аукционның бер адымына туры килә торган калган өлешен һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәч бирелә.

Әгәр электрон мәйданчык операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта лицензия проекты һәм лицензия килешүе урнаштырылган датадан соң 10 эш көне эчендә Аукционның бердәнбер катнашучысы Аукционны оештыручыга әлеге документларның имзаланган проектларын тапшырмаса һәм Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсәтелгән счетка бер тапкыр түләнергә тиешле сумманың калган өлешен күчермәсә һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләмәсә, Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.».

2. Боерык белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукцион үткәрүнең үрнәк тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Түләүләр һәм җыемнар

6.1. «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 42 статьясы нигезендә җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы билгеләгән тәртип нигезендә Аукционда катнашкан өчен җыем күләме ______________ сум тәшкил итә һәм гариза бирүче счетына барлык катнашучылар тарафыннан күчерелә.

Аукционда катнашу өчен җыем анда катнашучыларга кире кайтарылмый.

6.2. Аукционда катнашучыларның барысы да гаризалар биргәнчегә кадәр алдан түләү килешүе нигезендә бер тапкыр түләнә торган түләү күләмен түли.

6.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләнә торган түләүнең старт күләме (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу өчен бер тапкыр түләү) ____ сум күләмдә билгеләнә, ә Аукцион адымы – шуның 10%ы.

Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында Аукцион адымына тигез зурлыкта, агымдагы тәкъдимнәрне арттып җибәрүне күздә тоткан тәкъдимнәрен җиткерә.

Аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү калдыгы (алдан түләнгән сумманы тотып калган өчен гариза бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән бер тапкыр түләү суммасы) Аукционда җиңүче тарафыннан, әлеге Бертөр тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә, реквизитлар буенча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә лицензия килешүе проектын җибәргән көннән алып 10 календарь көне эчендә кертелә.

6.4. Лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, әлеге Бертөр тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә реквизитлар буенча 7 500 (җиде мең биш йөз) сум күләмендә кертелә.

6.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләр һәм файдалы казылмалар чыгаруга салым түли, аларның ставкасы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6.6. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка салымнарны һәм җыемнарны түли.»;

7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Аукцион ________________________________________ үткәрелә.
(Аукционны үткәрү датасы һәм вакыты)

Аукцион уздырылуы турындагы мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатулар уздырылуы турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен Россия Федерациясе рәсми сайтында www.torgi.gov.ru, Министрлыкның рәсми сайтында https://eco.tatarstan.ru урнаштырыла (Аукцион электрон формада http://sale.zakazrf.ru сайтында уздырылган очракта).

Белешмәләр өчен телефон: (843) 267-68-47.»;

11.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.2. Әгәр Аукцион әлеге Типлаштырылган тәртипнең 11.1 пунктындагы «а»-«г», «е» һәм «ж» пунктчаларында каралган нигезләр буенча узмаган дип танылса, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү әлеге Боерык белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына Аукцион Үрнәк тәртипнең 11.1 пунктындагы «д» һәм «з» пунктчаларында каралган нигез буенча узмаган дип танылса, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы Аукционда бердәнбер катнашучыга яисә Аукционда катнашып, бер тапкыр түләүнең башлангыч күләмен раслаган затка Аукцион шартларында, җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә, ул бер тапкыр түләнә торган түләүнең Аукционның бер адымына туры килә торган калган өлешен һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәч бирелә.

Әгәр электрон мәйданчык операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта лицензия проекты һәм лицензия килешүе урнаштырылган датадан соң 10 эш көне эчендә Аукционның бердәнбер катнашучысы Аукционны оештыручыга әлеге документларның имзаланган проектларын тапшырмаса һәм Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсәтелгән счетка бер тапкыр түләнергә тиешле сумманың калган өлешен күчермәсә һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләмәсә, Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән

файдалану хокукын бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.».

3. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

Министр А.В. Шадриков